СОВЕТ ПИЖМАРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ПЫЖМАРА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.09.2018 ел № 85

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Пыжмара авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, «Пыжмара авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2018 елның 18 сентябрендәге 84 номерлы Пыжмара авыл җирлеге Советы карары, « Пыжмара авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2018 елның 18 сентябрендәге 24 номерлы Пыжмара авыл җирлеге Башкарма комитеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2019 елда Пыжмара авыл җирлегендә яшәүче 18 яше тулган, референдумда тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

- Әтнә авылында: Малая, Комсомол, Искәндәров урамнарындагы

юлларны ремонтлау; авылны су белән тәэмин итүне капиталь ремонтлау проектын эшләү;

- Югары Сәрдек авылында: Заря урамы буенча янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру;

- Пыжмара авылында: С. Мөлеков урамы буенча балалар уен һәм спорт мәйданчыгын сатып алу, урнаштыру һәм киртәләү, Пыжмара авылы чишмәсе юлын ремонтлау, Г. Тукай урамы буенча юлга җәяүлеләр күпере сатып алу һәм монтажлау, авылны су белән тәэмин итү челтәренең су резервуары мәйданчыгы периметрын коймалау;

- Сәрдек авылында: Мир урамында су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау, су башнясы алу һәм урнаштыру, комплектлаучы ике янгын колонкасы сатып алу;

- Иске Пукшер авылында: суэтем башнясын ремонтлау, су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау;

ЮК ӘЙЕ".

3. Пыжмара авыл җирлеге Советы карары нигезендә, аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җыелган акчаны экономияләү очрагында, экономияләнгән акчалар референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелә.

4. Әлеге карарны «Хезмәт» район газетасында һәм pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар аңа имза куелган көннән үз көченә керә.

Пыжмара авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Җәләев